# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында

Әлеге Закон җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар, шул исәптән аларны арендалаучылар хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

<u>1 статья.</u> Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр:

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы - культуралы үсемлекләрнең туклыклы матдәләргә, дымга, һавага, җылыга, биологик һәм физик-химик мохиткә булган ихтыяҗларын туфракның канәгатьләндерә алуы һәм авыл хуҗалыгының культуралы үсемлекләреннән уңыш тәэмин итә алуы;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан нормалаштыру - авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызуны тәэмин итү өлкәсендә стандартлар, нормалар, нормативлар, кагыйдәләр, регламентлар билгеләү;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу - эрозиягә каршы, агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, культура-техник һәм башка чараларны системалы үткәрү юлы белән авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын саклау һәм арттыру;

авыл хуҗалыгы җирләренең деградацияләнүе - табигый һәм антропоген йогынтылар нәтиҗәсендә авыл хуҗалыгы җирләре уңдырышлылыгының үзенчәлекләре начараю;

авыл хуҗалыгы җирләренең пычрануы - туфракта кеше сәламәтлегенә, әйләнә-тирә табигать мохитенә, авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгына зарарлы йогынты ясарлык күләмнәрдә химик кушылмаларның, радиоактив элементларның, патоген организмнарның артуына китерү процессы;

агротехник чаралар - авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу максатларында туфракны эшкәртүнең фәнни нигезләнгән алымнары җыелмасы;

агрохимикатлар - үсемлекләрне тукландыру, туфракның ундырышлылыгын җайга салу өчен билгеләнгән ашламалар, химик мелиорантлар;

пестицидлар - үсемлек корткычларына һәм авыруларына, чүп үләннәренә, саклаудагы авыл хуҗалыгы продукциясе корткычларына, көнкүреш корткычларына каршы көрәштә файдаланылучы, шулай ук үсемлекләрнең үсүен көйләү, яфракларны урак алдыннан койдыру (дефолиантлар), үсемлекләрне урак алдыннан киптерү (десикантлар) өчен файдаланылучы химик һәм биологик препаратлар;

агрохимик чаралар - туфракның ундырышлылыгын торгызу, культураларның уңышлылыгын арттыру һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау максатларында агрохимикатларны, пестицидларны кулланунын фәнни нигезләнгән алымнары җыелмасы;

мелиоратив чаралар - мелиоратив системаларны һәм аерым урнашкан гидротехник корылмаларны проектлау, төзү, эксплуатацияләү һәм реконструкцияләү, көтүлекләрне дымландыру, урман үсентеләрен яклау системаларын төзү, культура-техник эшләрне башкару;

фитосанитар чаралар - туфракның чүп үләннәре белән чүпләнүен, туфракның авыл хуҗалыгының культуралы үсемлекләре авырулары һәм корткычлары белән зарарлануын ачыклау һәм аларны бетерүнең фәнни нигезләнгән алымнары җыелмасы;

эрозиягә каршы чаралар - туфракны су, җил һәм механик эрозиядән яклауның фәнни нигезләнгән алымнары җыелмасы;

культура-техник чаралар - туфрак өстен һәм аның эшкәртелүче катлавын агач-куак үсемлекләреннән, ташлардан арындыру, өслекне планлаштыру һәм тигезләү, авыл хуҗалыгы җирләренең продуктлылыгын арттыруны тәэмин итүче башка төрле эшләр буенча фәнни нигезләнгән алымнар җыелмасы;

агрохимик хезмәт күрсәтү - авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрне агрохимикатлар һәм пестицидлар, торф һәм аны эшкәртү продуктлары, гипс, известьлы һәм органик ашламалар, технологияләр, техника белән тәэмин итү эшчәнлеге, шулай ук агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, эрозиягә каршы һәм башка төрле гамәлләрне башкару, авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә фәнни тикшеренүләр уздыру эшчәнлеге;

авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын мониторинглау - авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгы торышын системалы рәвештә күзәтеп тору (сурәткә төшерүләр, эзләнүләр һәм тикшеренүләр).

**2 статья.** Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне хокукый җайга салу

Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне хокукый җайга салу Татарстан

Республикасының Җир кодексы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка төрле норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

**3 статья.** Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның, шул исәптән аларны арендалаучыларның хокуклары

Җир кишәрлекләре милекчеләре, аларны биләүчеләр, алардан файдаланучылар, шул исәптән аларны арендалаучылар түбәндәге хокукларга ия:

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы өчен фәнни нигезләнгән тәкъдимнәргә таянып, авыл хуҗалыгында куллану өчен рөхсәт ителгән агрохимикатларны, пестицидларны да кертеп, агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, эрозиягә каршы һәм культура-техник чаралар үткәрергә;

үзләренең җир кишәрлекләрендә туфрак уңдырышлылыгының торышы һәм аның торышын үзгәртү динамикасы турында законнарда билгеләнгән тәртиптә дөрес мәгълүмат алырга;

юридик затлар һәм гражданнар гаебе белән туфракның уңдырышлылыгы кимү нәтиҗәсендә килгән зыянны законнар нигезендә түләттерергә;

аларны гамәлгә ашыру законнарның таләпләренә каршы килмәсә, башка хокукларга ия булырга.

**4 статья.** Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә җир кишәрлекләре милекчеләренең, аны биләүчеләрнең, аннан файдаланучыларның, шул исәптән аларны арендалаучыларның бурычлары

Җир кишәрлекләре милекчеләре, аны биләүчеләр, аннан файдаланучылар, шул исәптән аларны арендалаучылар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүче, шулай ук шундый эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмаучы яисә чикләүче алымнар белән хуҗалык эшчәнлеген башкарырга;

агротехник, агрохимик, фитосанитар, мелиоратив, эрозиягә каршы һәм культура-техник чараларны үткәрү стандартларын, нормаларын, нормативларын, кагыйдәләрен һәм регламентларын үтәргә;

дәүләт идарәсенең тиешле органнарына агрохимикатлар һәм пестицидлар куллану турында мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә бирергә;

авыл хуҗалыгы җирләрен туфрак, агрохимик, фитосанитар һәм экологик-токсикологик тикшеренүләрне үткәрүдә ярдәм итәргә;

үз милкендә, биләвендә, файдалануында, шул исәптән арендалавында булган авыл хуҗалыгы җирләренең деградацияләнүе, пычрануы фактлары турында дәүләт идарәсенең тиешле органнарына хәбәр итәргә;

гамәлдәге законнарда каралган башка бурычларны үтәргә.

<u>5 статья.</u> Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне дәүләт тарафыннан җайга салу

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне дәүләт тарафыннан җайга салу түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә законнар һәм башка төрле норматив хокукый актлар әзерләү, кабул итү һәм әлеге актларны үтәүне тикшереп тору;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә инвестиция сәясәтен тормышка ашыру;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе.

<u>6 статья.</u> Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органнары тормышка ашыра.

<u>7 статья.</u> Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан тәэмин итү

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан тәэмин итү түбәндәге төп юнәлешләр буенча башкарыла:

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүнең максатчыл программаларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру, әлеге программаларның үтәлешен тикшереп тору;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышына Татарстан Республикасында җирләрнең торышы турында дәүләт доклады рәвешендә еллык анализ;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу һәм алардан оптималь файдалану гамәлләрен финанс, ресурс, җитештерү, фәнни яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын арттырган өчен, эрозиягә каршы чаралар комплексын керткән, җирдән файдаланучылар территориясендәге табигый туфрак комплексларын, махсус саклanылучы табигый территорияләрне саклап калган өчен җир кишәрлекләре милекчеләрен, аларны биләүчеләрне, алардан файдаланучыларны, шул исәптән аларны арендалаучыларны икътисадый кызыксындыру;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәпкә алуы һәм авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышын мониторинглау;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә мәгълүмати белешмәләр банкын булдыру;

авыл хуҗалыгы җирләрендә махсус бүленгән туфрак кишәрлекләрен билгеләү һәм исәпкә алу һәм аларның торышын мониторинглау;

радионуклидлар, авыр металлар һәм башка зарарлы матдәләр белән пычранган авыл хуҗалыгы җирләрен торгызу буенча чаралар планын әзерләү;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар һәм эрозиягә каршы чаралар үткәрү планнарын әзерләү;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге законнарның үтәлешен дәүләт тикшереп торуы;

туфракны, агрохимикатларны һәм пестицидларны сертификацияләү;

агрохимик хезмәт күрсәтү эшчәнлеген федераль законнар нигезендә лицензияләү;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү максатларында файдаланылучы агрохимикатларның һәм пестицидларның сыйфатын һәм алар белән хәвефсез эш итүнең куркынычсызлыгын тикшереп тору;

җир кишәрлекләре милекчеләренә, алардан файдаланучыларга, аларны биләүчеләргә һәм аларны арендалаучыларга аларның гаризалары буенча авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү һәм агрохимик хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү.

8 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү программалары

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү максатларында авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүнең республика программалары әзерләнә һәм гамәлгә ашырыла.

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүнең республика программалары нигезендә авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүнең җирле программалары законнар нигезендә әзерләнә һәм гамәлгә ашырыла.

9 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан нормалаштыру

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан нормалаштыру федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

10 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәбенә алу

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәбенә алу авыл хуҗалыгы җирләрен туфрак, агрохимик, фитосанитар, экологик-токсикологик тикшеренүләрдән һәм авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы мониторингы нәтиҗәләрен җыюдан һәм гомумиләштерүдән гыйбарәт.

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәбенә алу белешмәләре Татарстан Республикасы дәүләт җир кадастрының состав өлеше була.

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәбенә алу федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

11 статья. Агрохимик хезмәт күрсәтү

Агрохимик хезмәт күрсәтү, оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар тарафыннан башкарыла.

Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар үз эшчәнлекләрен координацияләү, гомуми мәнфәгатьләрне яклау максатларында законнар нигезендә ассоциацияләр (берлекләр) рәвешендәге берләшмәләр төзи алалар.

12 статья. Агрохимик хезмәт күрсәтүнең төп юнәлешләре

Агрохимик хезмәт күрсәтү түбәндәге юнәлешләрдә башкарыла:

туфрак, агрохимик, фитосанитар, экологик-токсикологик тикшеренүләр үткәрү;

авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итү максатларында агрохимик, фитосанитар, мелиоратив һәм эрозиягә каршы гамәлләр уздыру;

авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрне агрохимикатлар, пестицидлар, торф һәм аны эшкәртү продуктлары, гипс, известь һәм органик ашламалар белән тәэмин итү.

**13 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итүгә экологик таләпләр**

Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итү законнарда билгеләнгән экологик таләпләрне үтәү шартларында тормышка ашырыла.

**14 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт тарафыннан тикшереп тору**

Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт тарафыннан тикшереп тору үз компетенцияләре чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, шул исәптән җирләрдән файдалануны һәм аларны саклауны тикшереп торучы махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт тарафыннан тикшереп тору бурычлары җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларны биләүчеләрнең, алардан файдаланучыларның, шул исәптән аларны арендалаучыларның агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, эрозиягә каршы һәм культура-техник гамәлләрне уздыруның билгеләнгән тәртиптә расланган таләпләрен, нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итүдән гыйбарәт.

Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.

**15 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең ундырышлылыгы торышын мониторинглау**

Авыл хуҗалыгы җирләренен ундырышлылыгы торышын дәүләт тарафыннан мониторинглау Татарстан Республикасы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглауның состав өлеше була һәм җир турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

16 статья. Авыл хуҗалыгы җир кишәрлекләренең туфракларын, агрохимикатларны, пестицидларны сертификацияләү

Авыл хуҗалыгы җир кишәрлекләренең туфраклары, агрохимикатлар, пестицидлар мәҗбүри рәвештә сертификацияләнергә тиеш.

Авыл хуҗалыгы җир кишәрлекләре туфракларын, агрохимикатларны, пестицидларны сертификацияләү федераль законнар нигезендә башкарыла.

17 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлеккә дәүләт ярдәменең төп юнәлешләре

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлеккә дәүләт ярдәменең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызуга юнәлтелгән инвестиция эшчәнлеген кызыксындыру;

дәүләт агрохимия хезмәте инфраструктурасын булдыру һәм үстерү;

агрохимикатлар, пестицидлар җитештерүгә, сатып алуга, әзерләүгә һәм куллануга, агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, эрозиягә каршы, культура-техник гамәлләрне башкару өчен технологик машиналарны һәм җиһазларны җитештерүгә, сатып алуга, шулай ук күрсәтелгән гамәлләрне үткәрүгә дәүләт заказын урнаштыру;

проект-эзләнү, тикшеренү эшләрен оештыру, шулай ук авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын торгызу һәм аннан оптималь файдалану буенча фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләр оештыру;

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә кадрлар әзерләүне, аларны яңа һөнәргә өйрәтүне һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыру.

18 статья. Деградацияләнгән һәм пычранган авыл хуҗалыгы җирләрен консервацияләү

Авыл хуҗалыгы җирләренең деградацияләнүе үсешен кисәтү һәм аның барышын туктату, җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу һәм пычранган территорияләрне торгызу өчен әлеге җирләрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә консервацияләү карала.

Деградацияләнгән җирләрне торгызу ысулына һәм аларның пычрану дәрәҗәсенә карап консервацияләү урынына әлеге җирләрдән

файдаланунын махсус режимы кертелергә яисә аларның максатчан билгеләнеше үзгәртелергә мөмкин.

19 статья. Зарарлы матдәләр концентрацияләренең һәм туфракта эрозия процесслары нәтиҗәсендә алар юылунын мөмкин булган иң чик нормативларын билгеләү

Авыл хуҗалыгы җирләренең торышы күрсәткечләрен бәяләү өчен туфрактагы пычраткыч матдәләрнең һәм зарарлы биологик объектларның иң чик мөмкин концентрацияләренең нормативлары билгеләнә.

Эрозия процессларын булдырмый калу өчен туфракның һәр тибы һәм туфракның эрозияләнү дәрәҗәсе өчен юылуның иң чик мөмкин нормативлары билгеләнә.

Әлеге нормативлар һәм аларны билгеләү ысуллары федераль законнар нигезендә әзерләнә һәм раслана.

20 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне финанслау

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне финанслау түбәндәгеләр исәбеннән башкарылырга мөмкин:

федераль бюджет акчаларыннан;

Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан;

җирле бюджетлар акчаларыннан;

кредит оешмалары кредитларыннан;

законда тыелмаган башка чыганаклардан.

21 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын арттыру чараларын матди-техник тәэмин итү

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт заказчыларын билгеләү аша агрохимик хезмәт күрсәтүне үстерүгә булышлык күрсәтәләр, соңгылары түбәндәгеләргә заказларны урнаштыралар:

авыл хуҗалыгы продукциясен житештерүчеләр өчен агрохимикатлар, пестицидлар җитештерүгә, әзерләүгә, сатып алуга һәм куллануга;

агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, эрозиягә каршы һәм культура-техник гамәлләрне башкаруга;

агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, эрозиягә каршы һәм культура-техник гамәлләрне башкару өчен технологик машиналар һәм җиһазлар җитештерүгә, сатып алуга.

22 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә фәнни тикшеренүләр

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә түбәндәгеләрне әзерләү буенча фәнни тикшеренүләр үткәрелә:

авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү буенча фәнни-тикшеренү программаларын;

җирләрнең табигать-авыл хуҗалыгы буенча районлаштырылуын исәпкә алып, туфрак уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен;

туфракның торышын бәяләү һәм аларның уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен исәпкә алу методикаларын;

туфрактагы пычраткыч матдәләр һәм зарарлы биологик объектлар концентрациясенең иң чик мөмкин нормативларын;

авыл хуҗалыгы җирләренең мәйдан берәмлегенә йөкләнешнең мөмкин булган иң чик нормаларын, агрохимикатлар һәм пестицидлар куллануның иң чик мөмкин дәрәҗәсен;

агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар, эрозиягә каршы һәм культура-техник чаралар үткәрү технологияләрен, шулай ук торф чыгару һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерү технологияләрен;

нәтиҗәле һәм экологик яктан куркынычсыз агрохимикатларны һәм пестицидларны;

авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләрне авыл хуҗалыгы җирләренең торышы турындагы һәм агротехник хезмәт күрсәтү турындагы мәгълүмат белән тәэмин итү системаларын;

авыл хуҗалыгында озак вакытлар файдалану йогынтысында туфракның үзенчәлекләре үзгәрүнең норматив күрсәткечләрен;

авыл хуҗалыгының деградацияләнгән һәм пычранган җирләрен рекультивацияләү һәм реабилитацияләү алымнарын.

23 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә законнарны бозган өчен җаваплылык

Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә законнарны бозу законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

24 статья. Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә законнарны бозып китерелгән зыянны түләттерү

Гражданнар, юридик затлар авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә законнарны бозу нәтиҗәсендә үзләре китергән зыянны законнарда билгеләгән тәртиптә түләргә тиешләр.

25 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 24 гыйнвары

№ 595